РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 17 августы** **Чистай шәһәре** **№ 16/5**

Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 28 октябрендәге 2/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 мартындагы 65-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 28 октябрендәге 2/3 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карары белән расланган «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибенә, 1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1.7. Муниципаль гарантиягә бәйле йөкләмәләр муниципаль бурыч составына муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләр принципалының фактта булган суммасында, әмма муниципаль гарантия суммасыннан артмаска тиеш. Муниципаль гарантия бирү һәм үтәү муниципаль бурыч китабында чагылыш табарга тиеш.».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов